# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Горшково авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

2022 елның 21 октябре №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 17.10.2022 елның 13.00 сәгатендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Горшково авылында узган гражданнар Җыенының йомгак беркетмәсе төзелде:«Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Горшково авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан,1 төркем инвалидлардан кала, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:
- юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр өчен түләү);
-җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- Болын урамында балалар уен мәйданчыгын сатып алу, реконструкцияләү һәм урнаштыру (җиһазлар, материаллар сатып алу һәм шартнамә буенча эшләр өчен түләү) ;
-- авыл эчендәге юлларны ремонтлау (сатып алу, ташу, материал салу, килешү буенча эшләр өчен түләү)».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
Җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 107 кеше кертелгән, 68 кеше тавыш бирүдә катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:
«Әйе» позициясе өчен - гражданнар җыенында катнашкан 68 кеше тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Горшково авылында гражданнар җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.

2. «Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Ленино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан,1 төркем инвалидлардан кала, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:
- юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр өчен түләү);
-җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- Болын урамында балалар уен мәйданчыгын сатып алу, реконструкцияләү һәм урнаштыру (җиһазлар, материаллар сатып алу һәм шартнамә буенча эшләр өчен түләү) ;

-- авыл эчендәге юлларны ремонтлау (сатып алу, ташу, материал салу, килешү буенча эшләр өчен түләү)», карарын кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар Җыенының нәтиҗәләрен кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Ленино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында: http://novosheshminsk.tatarstan.ru/,» Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: (httr://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Ленино авыл җирлеге башлыгы С.Ю.Питеркина